**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 март № 177

г. Казань

Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында

«Күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-221 нче Федераль законның 42.10 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе эшенең бертип регламентын расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\177.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 20 март, 177 нче
карары белән расланды

Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре
чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе
эшенең бертип регламенты

1. Бу Бертип регламент «Күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-221 нче Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 42.10 статьясындагы 5 өлеше нигезендә эшләнде һәм комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) эшенең бертип тәртибен билгели.

Килештерү комиссиясенең эш регламенты аны төзегән орган тарафыннан раслана.

2. Комиссия территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган шәһәр округының яки җирлекнең җирле үзидарә органы комплекслы кадастр эшләрен башкаруга контракт төзегән көннән егерме эш көне эчендә төзелә.

3. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм Комиссиянең башка әгъзаларыннан тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Комиссия утырышы датасын билгели һәм көн тәртибен раслый, Комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя.

Комиссия рәисе урында булмаса, аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия сәркатибе Комиссия эшен тәэмин итә, шул исәптән Комиссия әгъзаларына утырышларның датасы һәм вакыты турында хәбәр итә, Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча эш башкару алып бара, материалларны саклауны һәм аларны алга таба архивка тапшыруны тәэмин итә, Комиссиянең эш тәртибе буенча консультация бирә.

Комиссия составына түбәндәгеләрдән берәр вәкил кертелә:

1) кадастр мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органыннан;

2) федераль милектәге тиешле күчемсез мөлкәт объектларына карата милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлекчәләреннән;

3) территорияләрендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган шәһәр округының яки җирлекнең җирле үзидарә органыннан, шулай ук муниципаль районның җирле үзидарә органыннан, әгәр аның территориясе составына күрсәтелгән җирлекләр керсә;

4) кадастр исәбе органыннан;

5) күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнан;

6) әгъзасы кадастр инженеры булган үз эшчәнлеген үзе җайга салучы оешмадан (әгәр дә ул үз эшчәнлеген үзе җайга сала торган оешма әгъзасы булса).

4. Комиссия составына, бу Бертип регламентның 3 нче пунктында күрсәтелгән вәкилләр белән беррәттән, территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган шәһәр округының яки җирлекнең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле җирле үзидарә органының вәкаләтле вәкиле һәм гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек яки коммерциягә карамаган дача берләшмәләре идарәләре рәисләре (әгәр комплекслы кадастр эшләре гражданнарның мондый берләшмәләр территорияләрендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектларына карата башкарылса) кертелә.

5. Комиссия рәисе булып территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган шәһәр округы яки җирлек башлыгы йә ул вәкаләт биргән зат тора.

6. Комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләләре буенча Комиссия вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынга карата бу Бертип регламентның 7 нче пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларның каршы килә торган фикерләрен карау;

2) җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынга карата бу Бертип регламентның 7 нче пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларның каршы килә торган фикерләрен карау нәтиҗәләре турында, шул исәптән мондый каршы фикерләр дәлилсез булган очракта, территориянең карта-планы проектын үзгәртүнең максатка яраксыз булуы яки мондый каршы килә торган фикерләр нигезендә территориянең комплекслы кадастр карта-планын комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан үзгәртергә кирәк булу хакында килештерү комиссиясе бәяләмәсен әзерләү;

3) комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләр урнашкан урынны килештерү актын рәсмиләштерү;

4) бу Бертип регламентның 7 нче пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларга җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урын турындагы җир бәхәсен суд тәртибендә хәл итү мөмкинлеген аңлату.

Комиссиянең беренче утырышы комплекслы кадастр эшләре заказчысына территориянең карта-планы проекты кергән көннән утыз эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә. Комиссиянең башка утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә.

Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы булып санала.

Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булса, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч була.

7. Чикләр урнашкан урынны килештерү түбәндәге хокуктагы арадаш җир кишәрлекләренә ия булган затлар тарафыннан үткәрелә:

1) милек хокукындагы (дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган мондый арадаш җир кишәрлекләре гражданнарга гомер буе мирас буларак ия булырга, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга йә дәүләт учреждениеләре яки муниципаль учреждениеләр йә казна предприятиеләре булмаган юридик затларга даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

2) гомер буе мирас буларак ия булу хокукындагы;

3) даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукындагы (мондый арадаш җир кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә яки муниципаль учреждениеләргә, казна предприятиеләренә, дәүләт хакимияте органнарына яки җирле үзидарә органнарына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

4) аренда хокукындагы (әгәр мондый арадаш җир кишәрлекләре дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булса һәм тиешле аренда шартнамәсе иң киме биш елга төзелгән булса).

8. Комплекслы кадастр эшләре объектлары булган һәм бу эшләрне башкару территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү максатларында, Комиссия бу Бертип регламентның 9 нчы пунктында билгеләнгән тәртиптә бу Бертип регламентның 7 нче пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар һәм комплекслы кадастр эшләрен башкаручы чакырыла торган утырыш үткәрә.

9. Җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләсе буенча шул исәптән территориянең карта-планы проектын әзерләп бетерү хакындагы хәбәрне үз эченә алган Комиссия утырышы үткәрелү турындагы хәбәрнамә комплекслы кадастр эшләрен башкара башлаган вакыт турындагы хәбәрнамәне бастырып чыгару, урнаштыру һәм җибәрү өчен Федераль законда билгеләнгән ысуллар белән әлеге утырышны үткәрү көненә кимендә унбиш эш көне кала комплекслы кадастр эшләре заказчысы тарафыннан бастырып чыгарыла, урнаштырыла һәм җибәрелә.

Җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләсе буенча Комиссия утырышын үткәрү турындагы хәбәрнамәнең үрнәк формасы һәм эчтәлеге Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

10. Кызыксынучы затларны комплекслы кадастр эшләрен башкарганда билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урын белән таныштыруны тәэмин итү максатларында, комплекслы кадастр эшләре заказчысы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз рәсми сайтында (рәсми сайты булганда) территориянең карта-планы проектын җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы үткәрелү турындагы хәбәрнамә белән бер үк вакытта урнаштыра һәм күрсәтелгән документларны түбәндәгеләргә җибәрә:

1) кадастр мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органына – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру өчен;

2) кадастр исәбе органына – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз рәсми сайтында урнаштыру өчен;

3) килештерү комиссиясенә.

11. Кадастр мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, кадастр исәбе органы бу Бертип регламентның 10 нчы пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән иң күбе өч эш көне эчендә җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләсе буенча Комиссия утырышы үткәрелү турындагы хәбәрнамәне һәм территориянең карта-планы проектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз рәсми сайтларында урнаштыра.

12. Комиссия теләсә кайсы затны территориянең карта-планы проекты белән (шул исәптән кәгазь чыганактагы документ рәвешендә) җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләсе буенча Комиссия утырышы үткәрелү турында хәбәрнамә басылып чыккан көннән беренче утырыш үткәрелгән көнгә кадәрге чорда, шулай ук Комиссиянең беренче утырышы үткәрелгән көннән утыз биш эш көне эчендә таныштыруны тәэмин итә.

13. Җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләсе буенча Комиссия утырышында территориянең карта-планы проекты тәкъдим ителә, комплексны кадастр эшләрен башкару нәтиҗәләре,  җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү тәртибе һәм килештерү комиссиясенең эш регламенты аңлатыла.

14. Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләренең урнашкан урыны килештерү чикләре урнашкан урыннары Федераль закон нигезендә мәҗбүри килештерелергә тиешле  җир кишәрлекләренә карата үткәрелә.

15. Федераль законның 42.1 статьясындагы 1 өлешенең 1 нче һәм 2 нче пунктларында күрсәтелгән  җир кишәрлеге чикләре урнашкан урынга карата бу Бертип регламентның 7 нче пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затның каршы килә торган фикерләре җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы үткәрелү турында хәбәрнамә бастырып чыгарылган көннән беренче утырыш үткәрелгән көнгә кадәрге чорда, шулай ук килештерү комиссиясенең беренче утырышын үткәргән көннән утыз биш эш көне эчендә Комиссиягә язма рәвештә кертелергә мөмкин.

16. Җир кишәрлеге чикләре урнашкан урынга карата каршы килә торган фикерләр бу каршы килүче фикерләрне җибәргән зат турындагы мәгълүматларны, шул исәптән аның фамилиясен, исемен һәм (булганда) атасының исемен, шулай ук хокук иясенең адресын һәм (яки) хокук иясенең электрон почта адресын, шәхесен таныклый торган документы реквизитларын, аның җир кишәрлеге чикләре урнашкан урын белән килешмәү сәбәпләре нигезләвен, җир кишәрлегенең кадастр санын (булганда) яки территориянең карта-планы проекты нигезендә ясала торган җир кишәрлеге билгесен үз эченә алырга тиеш. Күрсәтелгән каршы килә торган фикерләргә бу каршы килә торган фикерләрне язып җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслый торган документларның күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеле яки таныклый торган башка документлар, шулай ук мондый җир кишәрлеге ясалганда (булганда) чикләр урнашкан урынны билгеләүче яки билгеләгән документлар теркәлергә тиеш.

17. Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләр урнашкан урынны килештерү актлары һәм Комиссиянең бу Бертип регламентның 6 нчы пунктындагы 2 нче һәм 3 нче пунктчаларда күрсәтелгән бәяләмәләре, Комиссия утырышы

үткәрелгән көннән өч эш көне эчендә Комиссия төзегән орган саклый торган кәгазь чыганактагы документлар рәвешендә Комиссия тарафыннан тутырыла.

Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләр урнашкан урынны килештерү актларына һәм Комиссия бәяләмәләренә Комиссия рәисе һәм сәркатибе, шулай ук Комиссия утырышын үткәргән көндә утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары кул куя.

18. Комплекслы кадастр эшләрен башкару кысаларында җир кишәрлеге чикләре яки чикләренең өлешләре урнашкан урынны килештергәндә мондый чикләр яки аларның өлешләре урнашкан урын дип түбәндәгеләр санала:

1) килештерелгән дип, әгәр җир кишәрлеге чикләре яки чикләренең өлешләре урнашкан урынга карата каршы килә торган фикерләр бу Бертип регламентның 7 нче пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан кертелмәсә, шулай ук әгәр мондый чикләр яки чикләрнең өлешләре урнашкан урын законлы көченә кергән суд акты нигезендә билгеләнсә, шул исәптән җир кишәрлеге чикләре урнашкан урын турындагы җир бәхәсе каралуга бәйле рәвештә;

2) бәхәсле дип, әгәр җир кишәрлеге чикләре яки чикләренең өлешләре урнашкан урынга карата каршы килә торган фикерләр бу Бертип регламентның 7 нче пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан кертелсә, моңа җир кишәрлеге чикләре урнашкан урын турындагы җир бәхәсе суд тәртибендә хәл ителгән очраклар керми.

19. Комиссиянең эш нәтиҗәләре буенча формасын һәм эчтәлеген Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгы раслый торган Комиссия утырышы беркетмәсе, шулай ук җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынга карата каршы килә торган фикерләрне карау нәтиҗәләре турында килештерү комиссиясе бәяләмәсе төзелә.

Комиссия беркетмәсен Комиссия сәркатибе алып бара, аңа Комиссия утырышы үткәрелгән көндә Комиссия рәисе һәм утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары кул куя.

20. Бу Бертип регламентның 15 нче пунктында каралган каршы килә торган фикерләрне кертү вакыты чыккан көннән егерме эш көне эчендә Комиссия комплекслы кадастр эшләре заказчысына комплекслы кадастр эшләрен башкаручы төзегән территория карта-планының соңгы редакциядәге проектын һәм Комиссия утырышының аны раслау өчен кирәкле материалларын раслау өчен җибәрә.

21. Бу Бертип регламент белән күздә тотылган комплекслы кадастр эшләре башкарылган җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү нәтиҗәсендә җайга салынмаган җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урын турындагы җир бәхәсләре комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләр урнашкан урынны килештерү актын рәсмиләштергәннән соң суд тәртибендә хәл ителә.

22. Комиссиянең бу Бертип регламент нигезендә расланган бәяләмәсе булу яки булмау территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урын турындагы җир бәхәсләрен хәл итү өчен судка мөрәҗәгать итүдә каршылык тудырмый.

---